
Чакмагыш үзәк биләмәара китапханәсе

**Сценарий**

**Дилбәр Булатованың «Наза» китабының китап туе**




**Чакмагыш - 2022**

**Талгын гына көй уйный**.

**1 алып баручы:**

Биек булмаса да тауларым бар,

Текә булса да - үрләрем.

Мин тормышта һәрбер биеклеккә

Хыялларым белән үрләдем...

Шагыйрь әйткәнчә, тормышта бөтен матур эшләр, күркәм гамәлләр дә хыялдан башлана. Якты уйлар, изге максатлар белән янган кешене уңыш бер дә читләп үтми. Ләкин ул хыялланып, алма пеш, авызга төш дип утырганнан гына килми, ә тырыш хезмәт нәтиҗәсе. Көч-тир түгеп яулап алганны ярата ул.

Язмышын шулай үзе язган уңган-тырышларны төрле өлкәләрдә очратырга мөмкин.

**Көй туктый.**

**2 алып баручы:** Хәерле көн, хормэтле кунаклар! Сезне шушы куркэм китапханэ уку залында курүебезгэ бик шатбыз! Буген бездэ зур бэйрэм. Чакмагыш районы Кашкар авылында туып-үскән якташыбыз Дилбэр Данис кызы Булатова бүген бездә кунакта.Дилбэр ханымнын туган якларына кайтуының топ сәбәбе – Зәйнәб Биишева исемендәге "Китап" нәшриятында "Наза" исемле китабы донья куреуе.

**1 алып баручы:** Бугенге бэйрэмебезгэ ерак араларны якынайтып хэм шатлыгыбызны уртаклашырга Уфадан кунаклар да килде. Алар белэн таныштырып утик эле:

Башкортстан Дәүләт Җыелышы-Корылтай депутаты, Башкортстан Язучылар берлеге рәисе, филология фәннәре кандидаты, Мифтахетдин Акмулла исемендәге Башкорт Дэулэт педагогия

университеты доценты, Башкортстанның атказанган мәгариф хезмәткәре **Зәки Арыслан улы Әлибаев.**

**<u>2 алып баручы:</u>** "Кызыл таң" гәзите, "Тулпар", "Әллүки" журналларының баш мөхәррире, филология фәннәре кандидаты, Башкортстанның атказанган матбугат һәм киңкүләм мәгълүмат хезмәткәре **Фаил Камил улы Фәтхетдинов**.

**<u>1 алып баручы:</u>** Башкортстан татарлары милли-мәдәни мохтариятенең башкарма директоры, филология фәннәре кандидаты, М. Акмулла исемендәге Башкорт Дәүләт педагогия университеты доценты, Башкортстанның атказанган мәгариф хезмәткәре **Альбина Габит кызы Хәлиуллина.**

**<u>2 алып баручы:</u>** "Тулпар" журналының баш мөхәррире урынбасары, Башкорт Дәүләт университеты доценты, филология фәннәре кандидаты, Башкортстанның атказанган матбугат һәм киңкүләм мәгълүмат хезмәткәре **Илдус Камил улы Фазлетдинов.**

**<u>1 алып баручы:</u>** "Тулпар" журналының шигърият, сатира-юмор бүлекләре мөхәррире, Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, шагыйрь **Мөнир Мәхмүт улы Вафин.**

**<u>2 алып баручы:</u>** Якташыбыз, "Өмет" гәзитенең хатлар бүлеге мөдире, Башкортстанның атказанган матбугат һәм киңкүләм мәгълүмат хезмәткәре **Гөлара Әнвәр кызы Арсланова.**

**<u>1 алып баручы:</u>** Шагыйрә, язучы, Башкортстанның мәгариф отличнигы **Гөлнара Зиннәтнур кызы Шәймөхәммәтова (Гөл Мирһади).**

**<u>2 алып баручы:</u>** Русия Федерациясе һәм Башкортостан Республикасы Журналистлар берлеге әгъзасы, Татарстан Язучылар берлегенең татар

телле әдәбиятчылар берләшмәсе бюросы әгъзасы, Вазыйх Исхаков исемендәге әдәби премия лауреаты, «Сәхипҗамал» Башкортстан Республикасы татар хатын-кызларының иҗтимагый оешмасы рәисе, Башкортстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, - **Динә Гайни кызы Мурзакаева.**

**1 алып баручы:** "Кызыл таң" гәзите журналисты **Зөһрә Наил кызы Исламова.**

**2 алып баручы:** Җырчы, композитор, рәссам **Флера Габделхәй кызы Шәрипова.**

**1 алып баручы:** Яшь җырчы, Захир Исмәгыйлев исемендәге Уфа дәүләт сәнгать академиясе студенты **Кадрия Илгиз кызы Исламова.**

Ә хәзер котлау өчен сүзне Башкортстан Республикасының Чакмагыш районы муниципаль район Хакимияте башлыгы **Реканс Фәнил улы Ямалеевка** бирәбез. Рәхим итегез! **Рәхмәт Реканс Фәнил улы.**

**2 алып баручы:** **Кадрия Исламова** чакмагышлыларга бүләккә матур җыр алып кайткан. Өметле яшь җырчыны тыңлап үтик әле, дуслар!

**1 алып баручы:** Сүз Башкортстан Республикасы Дәүләт Җыелышы-Корылтае Депутаты **Ирек Марс улы Усмановка бирелә.** Рәхим итегез! **Рәхмәт Ирек Марс улы.**

**2 алып баручы:** Сүз **Башкортстан Язучылар берлеге рәисе - Зәки Арслан улы Алибаевка.** Рәхим итегез! **Рәхмәт Зәки Арслан улы.**

**1 алып баручы:**. Сүз "Кызыл таң" гәзите, "Тулпар", "Әллүки" журналларының баш мөхәррире, филология фәннәре кандидаты, Башкортстанның атказанган матбугат һәм киңкүләм мәгълүмат хезмәткәре **Фаил Камил улы Фәтхетдиновка** бирелэ. Рәхим итегез! Рәхмәт!

**<u>2 алып баручы:</u>** Китапханә – рухи донья, китап сөючеләрне узенә тартып торган илахи көч. Сүзне шушы китаплар доньясынын хужабикәсе, житәкчебез – **Алсу Радик кызы Гәрәевага** бирәбез. Рәхим итегез! Рәхмәт **Алсу Радик кызы!**

**<u>1 алып баручы</u>:** Сүз Башкортстан татарлары милли-мәдәни мохтариятенең башкарма директоры, филология фәннәре кандидаты, М. Акмулла исемендәге Башкорт Дәүләт педагогия университеты доценты, Башкортстанның атказанган мәгариф хезмәткәре **Альбина Габит кызы Хәлиуллинага** бирелэ. Рәхим итегез!

**<u>2 алып баручы:</u>** Сүз "Тулпар" журналының баш мөхәррире урынбасары, Башкорт Дәүләт университеты доценты, филология фәннәре кандидаты, Башкортстанның атказанган матбугат һәм киңкүләм мәгълүмат хезмәткәре **Илдус Камил улы Фазлетдиновка** бирелә! Рәхим итегез!

**<u>1 алып баручы</u>:** «Туган як – язмышыңа язган як. Син нәкъ шул авылда, нәкъ шул гаиләдә дөньяга килгәнсең икән, димәк, юкка гына түгел… Кем ничектер, миңа үзебезнең кечкенә генә, бөтен яктан да диярлек урманнар әйләндереп алган, бәбкә үләнле, киң урамлы Кашкар дигән авылыбыз бик якын, бик кадерле. Туган якның суы да йомшаграк, кешеләре дә яхшырак, ягымлырак кебек. Башкача булу мөмкин дә түгел, чөнки бу туфракта минем эти-әнинең, икеяклап та ничәмә-ничә буын әби-бабайларның гомерләре үткән, маңгай тирләре тамган. Минем бөтен нәсел җепләрем шушы төбәккә: Кашкар, Калмашбаш, Почкак, Чакмагыш авылларына таралган.», - ди Дилбәр Булатова.

**Видео «Кашкар кызы».**

**<u>1 алып баручы</u>:** Әйе,Туган як һәркемнең күңел түрендә. Флера Шәрипова башкаруындагы моңлы җыр да шул хакта.

**<u>2 алып баручы</u>:** Шулай, кеше кайда гына, ничек кенә яшәсә дә, туган-үскән җирен, кендек каны тамган газиз туфрагын күңел түрендәге хисләр сандыгыннан алып ташлый алмый. Сагыну хисе аның рухына, кан тамырларына сеңгән. Әмма, кош балалары канат ныгыту белән зәңгәр күккә омтылган кебек, кешеләр дә еракларга карап юл тота, белем ала, хезмәттә үз юлын табарга тырыша.

**<u>1 алып баручы:</u>** Мәктәп елларында ук Дилбәр Булатова үзебезнең "Игенче" район газетасы оештырган "Яшь хәбәрләр" түгәрәгенә йөри башлый, мәкаләләре "Игенче"дә, "Башкортстан пионерлары", "Кызыл таң", "Өмет" газеталарында басылып чыга. Туган телгә, әдәбиятка мәхәббәт аны Башкорт дәүләт университетының татар-рус бүлегенә алып килә. 5нче курста укыганда ук республика "Тулпар" яшьләр журналына чакыру ала һәм бүгенге көндә дә бу анда бүлек мөдире булып эшен дэвам итэ. Башкортстан Язучылар берлегенең Татар әдипләре берләшмәсендә дә проза бүлеге өчен җавап бирә.

2005 елдан башлап "Китап" нәшриятында аның "Туй", "Көлдән яралган гөл", "Соң түгел" һәм "Наза" исемле чәчмә җыентыклары шулай ук башка әдәби, публицистик һәм фәнни-популяр китаплары дөнья күрде.

Бүген Дилбәр Данис кызы – филология фәннәре кандидаты, Башкортстанның атказанган матбугат һәм киңкүләм мәгълүмат хезмәткәре, Илдар Юзеев исемендәге әдәби премия лауреаты.

Дилбәр Данис кызының хезмәт эшчәнлеге хакында җентеклерәк итеп аның хезмәттәшләре сөйләр, мөгаен. Рәхим итегез! Рәхмәт!

**(Уфа кунакларга сүз бирелэ)**

**<u>2 алып баручы:</u>** Хөрмәтле Дилбәр Данис кызы!!! Без Сезнең белән очрашуны бик тә түземсезләнеп көтеп алдык. Дистәгә якын китабыгыз басылуга карамастан, якташларыгыз белән беренче тапкыр очрашасыз. Моның сәбәбе нидә микән?

**Дилбэр Булатова Сөйли.**

**СОРАУЛАР БИРЭБЕЗ:**

**– Белүебезчә, бүгенге очрашуыбызнын төп сәбәбе яна гына табадан төшкән "Наза" китабы. Аны без дә кызыксынып укып чыктык. Һәм шундый сорау калыкты: повестьтагы төп геройның прототибы кем?**

**– Әлеге вакыттаниндидер әсәр язасызмы?**

Бик зур рәхмәт кызыклы жавапларыгыз өчен.

Бугенге бәйрәмгә безнен курше Илеш районынан да кунаклар килгән. Хәзер котлау өчен сузне аларга бирәбез. Сүз "Балкыш" әдәби тугәрәге житәкчесе **Гөлфинә Салимовага.** Рәхим итегез!

Сүз Русия язучылар берләшмәсенен "Ел язучысы – 2021" конкурсы лауреаты **Илгиз Әхмэтовкә** бирелә. Рәхим итегез!

Сүз ижатчы Мәрьям Шәмсиевага бирелә! Рәхим итегез! Рәхмәт.

**<u>1 алып баручы</u>:** Хәзер котлау өчен сүзне "Игенче" район гәзите мөхәррире **Фәнис Фидан улы Әмирхановка бирелә. Рәхим итегез! Рәхмәт!**

Ә хәзер чыгыш ясыячак кунагыбыз, шул вакытта анын остазы булган, районда шигырь хәм проза язучыларны дөньяга чыгарган журналист, "Чакмагыш чаткылары" әдәби берләшмәсе җитәкчесе. Күп китаплар

авторы - **Рәзифә Гали кызы Сахапова. Сүз сезгә бирелә. Рәхим итегез! Рәхмәт Рәзифә ханым!**

**<u>Жыр. Лилия Арсланова</u> "<u>Туган туфрак</u>".**

Хөрмәтле кунаклар! Бәлки, сезнен арагыздан да кемнеңдер әйтеп китер сүзләре, теләкләре бардыр. Рәхим итегез. **(Чакмагыш чаткыларына сүз бирелэ).**

**<u>2 алып баручы</u>:** Кадерле кунакларыбыз! Кичәбез азагына да якынлашты. Бүгенге очрашуга килгән кунакларыбызга зур рәхмәт әйтәсебез килә. "Наза" китабы белән барыгыз да якыннан танышырсыз дигән теләктә калабыз. Үзәк китапханәсенә авторыбыз бүләк итте китабын. Теләүчеләр булса, рәхим итегез!

**<u>1 алып баручы</u>:** Хөрмәтле Дилбәр Данис кызы! Сезгә киләчәктә дә рух күтәренкелеге, ныклы сәламәтлек, әдәби эшчәнлегегездә уңышлар телибез. Иҗат чишмәгез саекмыйча, яңадан яңа язмаларыгыз белән безне сөендереп торыгыз!

Чакыруыбызны инкарь итмичә, элеге матур кичәдә катнашуыгызга тирән рәхмәтебезне белдерәбез, алда да бергә булыйк, бердәм булыйк! Киләсе очрашуларга кадәр сау булыгыз!